# КАРАР

**2024 елның 20 ноябре** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарас авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарс авылы торак пунктында гражданнар җыены хәл итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә ашыгыч хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хезмәт итүгә контракт имзалаган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларынан кала,1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- *җир асты суларының (чишмәләр) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү* (Манзарас авылы чишмәсе территориясен төзекләндерү һәм рәләү, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- *торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту* (Манзарас авылында урам челтәрен тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү),(Манзарас авылы юлларына асфальт салу, торбалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза уздыру; урамнарны вак таш җәелгән юлларны ремонтлау, проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; юлларны кышкы тоту, смета документларын төзү, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- *электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм*

*башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау* (Манзарас авылында бишенче линия төзү, проект-смета документациясен эшләү; (урам яктырту лампаларын, яктырткычларны, яктырткычларны, махсус җайланмаларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, Манзарас авылында махсус җайланмалар, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- *янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү* (янгын сүндерүчеләр гидрантларын һәм комплектлаучыларны сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, Манзарас авылында янгын гидрантларын комплектлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, эш һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- *торак пункт территориясен төзекләндерү* (Манзарас авылы янындагы территорияне төзекләндерү, спорт һәм балалар мәйданчыкларын төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру шартнамәсе буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; Манзарас авылында тротуарлар төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү шартнамәсе буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, техник күзәтчелекне башкару; яңгыр канауларын һәм канализацияләрен ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү шартнамәсе буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; кыргый чәчәкләрдән һәм агачлардан чистарту, яр буйларын ныгыту, материаллар сатып алу, смета документларын төзү, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- *су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау* (торбалар алыштыру, Манзарас авылына материаллар, җиһазлар сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

-*Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү* (һәйкәлләрне төзү, ремонтлау, янәшәсендәге территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм эшләү, шартнамә буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр).

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Манзарас авыл җирлеге башлыгы
урынбасары

В.М. Ахатов